| | |
|---|---|
| **БОЛГАРСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТСПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БОЛГАР ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 44 29.06. 2020 ел

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Болгар шәһәр Башкарма комитетының «Муниципаль милекне арендалау шартнамәсен өзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»2020 елның 10 февралендәге 15 номерлы карары белән расланган регламентка түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм административ регламентларны Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Болгар шәһәр башкарма комитеты

КАРАР БИРЭ:

1.Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Болгар шәһәр Башкарма комитетының «Муниципаль милекне арендалау шартнамәсен өзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 10 февралендәге 15 номерлы карары белән расланган административ регламентка түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 2.15 пунктындагы 13 абзацны төшереп калдырырга;

1.2. Административ регламентның 5 бүлегенең исемен яңа редакциядә бәян итәргә: «Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, шулай ук муниципаль хезмәтләр күрсәтү функцияләрен гамәлгә ашыручы оешмаларның яисә аларның хезмәткәрләренең карарларына (гамәл кылмауларына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка (судтан тыш) шикаять белдерү».

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (/http:pravo.tatarstan.ru) законда билгеләнгән вакытта бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Спас муниципаль районы
Болгар шәһәре Башкарма комитеты
җитәкче вазыйфаларын башкаручы И. А. Кузнецов